СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.07.2021 г.Зеленодольск № 49

Зеленодольск шәһәре Советының 2019 елның 26 декабрендәге 276 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе Сергеев П.Н. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының 2019 елның 26 декабрендәге 276 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 статьяның 10.1 пунктында. И1 – транспорт инфраструктурасы зонасы шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.8 | Иҗтимагый идарә | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 4.4 | Кибетләр | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 4.6 | Җәмәгать туклануы | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |

* РФ Икътисади үсеш министрлыгының 01.09.2014 ел, № 540 боерыгы белән расланган җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләре классификаторы нигезендә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск шәһәре Советының шәһәр төзелеше, торак сәясәте, төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет Рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА * ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ